**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Күңгәр авыл җирлеге Мөндеш торак пунктында**

# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

"25" ноябрь 2020 ел. № 2

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлегенең Мөндеш торак пунктында халык җыены

КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Мөндеш авылы территориясендә 2021 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлегенең Мөндеш авыл җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:

1.Җирле әһәмияттәге юлларга хезмәт күрсәтү:

- авыл урамына җәю өчен вак таш сатып алу, җәю һәм транспорт хезмәтләре өчен түләү;

2.Җирлек территориясен төзекләндерү һәм чистарту:

- авыл территориясен чистарту, хезмәтләр өчен түләү;

3. Урамнарны яктырту хезмәте күрсәтү:

- лампалар,автоматлар,җибәрү җайланмалары, таймерлар сатып алу, урнаштыру, һәм хезмәтләр өчен түләү;

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлегенең Мөндеш авылында яшәүче халык җыенының әлеге карарын Күңгәр авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4 Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Мөндеш авылында узган халык җыены карарын Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында
рәислек итүче,
Күңгәр авыл җирлеге башлыгы: Салахов И.И.